Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Урта Йорткүл авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар | Постановление

2020 елның 3 феврале | 1 номерлы

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Урта Йорткүл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр
күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә
торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Урта Йорткүл авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Урта Йорткүл авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Урта Йорткүл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2019 елның 13 мартының 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

4. Әлеге карарны Урта Йорткүл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Урта Йорткүл авыл җирлеге битендә Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spassriy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Урта Йорткүл авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Г. Р. Кәримуллина

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районының Урта Йорткүл авыл җирлеге башкарма
комитетының 2020 елның«3»феврале
1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Урта Йорткүл авыл җирлегендә вафат булган ир яисә хатынны, якын туганнарын, башка туганнарын яисә законлы вәкилләрен җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2166,30 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 928,48 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3030,08 |
| **Барлыгы:** | 6124,86 |

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районының Урта Йорткүл авыл җирлеге башкарма
комитетының 2020 елның«3»феврале
1 номерлы карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Урта Йорткүл авыл җирлегендә вафат булмаган ир яисә хатынны, якын туганнарын, башка туганнарын яисә законлы вәкилләрен җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1.Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тән кимү | 348,18 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1818,12 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 928,48 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3030,08 |
| **Барлыгы:** | **6124,86** |